РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БЮРГАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БОЕРГАН
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.07.2026 № 15

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Башкарма комитетының2026 елның 5 февралендән 1 номерлы «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Боерган авыл җирлеге территориясендә киселә торган яшел үсентеләр бәясен исәпләү һәм компенсацион яшелләндерү үткәрү методикасын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Буа муниципаль районы Боерган авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Башкарма комитетының 2026 елның 5 февралендән 1 номерлы «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Боерган авыл җирлеге территориясендә киселә торган яшел үсентеләр бәясен исәпләү һәм компенсацион яшелләндерү үткәрү методикасын раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Кушымтаның 1.3 һәм 1.4. пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Методика кулланыла: Буа муниципаль районы Боерган авыл җирлеге территориясендә яшел үсентеләргә кагылышлы хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашырганда килеп чыгарга мөмкин булган зыянны бәяләү өчен инвестиция проектларының әйләнә-тирә мохиткә йогынтысын бәяләү бүлекләрен әзерләү һәм аларга экологик экспертиза ясау барышында; табигать факторларын, шулай ук яшелләндерү объектларының экологик әһәмиятен исәпкә алып, яшел утыртмаларны законлы рәвештә кискән өчен түләү күләмен исәпләгәндә; яшел утыртмаларны хокуксыз зарарлаганда яисә юкка чыгарганда зыянны исәпләү Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә гамәлгә ашырыла, авыл җирлеге территориясендәге яшел утыртмаларның бәясен билгеләү белән бәйле башка очракларда, урман фонды җирләрендә үсә торган яшел утыртмалардан, шулай ук урман утыртмаларына кертелмәгән агачлар, куаклар һәм лианалар, аларның хокукый режимы Россия Федерациясенең урман законнары белән

җайга салынган очракларда. Әлеге Методика Боерган  авыл җирлеге чикләрендәге башка барлык яшел утыртмаларга (урман утыртмаларына кертелмәгән агачларны, куакларны һәм лианаларны да кертеп) карата тулы күләмдә кулланыла.»

1.4. Әлеге Методика Боерган  авыл җирлеге территориясендә үсә торган урманнарга һәм урман утыртмаларына урман законнарын бозу нәтиҗәсендә китерелгән зыянны исәпләп чыгаруга бәйле мөнәсәбәтләргә дә кагылмый. Барлык башка яшел утыртмаларга карата (урман утыртмаларына кертелмәгән агачларны, куакларны һәм лианаларны да кертеп, шулай ук торак пунктлар җирләрендә, юл буенда, паркларда, скверларда, йорт яны һәм янәшәдәге территорияләрдә үсүче) әлеге методика нигезләмәләре мәҗбүри тәртиптә кулланыла.»

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында  http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында http://buinsk.tatarstan.ru. урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы Буа муниципаль
районының Боерган  авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе                                   И.В.Малышева